МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.03.2022 г.Казань № 164

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 4 апрелендә 9017 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м :

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 5 февралендәге 55 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне кертергә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 05.03.2022
№ 164 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 593 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

3.4 пунктның икенче абзацында «һәм әлеге Нигезләмәнең $1^1$ кушымтасындагы үрнәк буенча тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси мәгълүматларны таратуга ризалык;» сүзләрен өстәргә;

Әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада «Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә шәхси белешмәләрнең эшкәртелүенә риза.» сүзләрен «Тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкны терким.» сүзләре белән алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле $1^1$ кушымтасын өстәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының 2018
елның 18 июлендәге 593 номерлы
боерыгы (Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
_______________ № ______ боерыгы
редакциясендә) белән расланган
Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәтенең вакантлы
вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертүгә) конкурс үткәрү
турындагы нигезләмәгә $1^1$ кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

**Тарату өчен рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык**

Мин,____________________________________________________________,

*(Ф.И.А. тулысынча)*

________________________________________________________________

(белешмә мәгълүматлар: шәхси белешмәләр субъектының телефон номеры, электрон почта адресы яисә почта адресы)

________________________________________________________________

________________________________________________________________,

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрү максатларында, шулай ук Конкурска йомгак ясау максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (420044, Казан ш., Волгоград урамы, 47 йорт; ОГРН 1071690050299) үземнең шәхси мәгълүматларымны: фамилия, исем, ата исеме; туган көн һәм туган урын; җенес; гражданлык; белем; гыйльми дәрәҗә; гыйльми исем; өстәмә һөнәри белем; һөнәр (белгечлек); эш стажы; эшкә керү, эштән икенче эшкә күчү, билгеләнү һәм эштән китүләр турында белешмәләр; гаилә хәле (шул исәптән: тормыш иптәше һәм балигълык яшенә җитмәгән балалар турында белешмәләр, аларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, туган көннәре); паспорт белешмәләре; теркәлү һәм яшәү урыны адресылары; элемтә өчен телефон номеры; дәүләт пенсия иминияте буенча иминиятләштерү таныклыгы номеры; салым түләүченең тәңгәллек номеры; әлеге дәүләт органында, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://gossluzhba.gov.ru) булган фотом сурәте буенча белешмәләрне (мәгълүматларны) эшкәртүгә (автоматлаштыру чараларын кулланып яисә андый чаралардан башка гына башкарыла торган теләсә нинди гамәлгә (операциягә) яки гамәлләр (операцияләр) җыелмасына, шулай ук минем шәхси мәгълүматларны (белешмәләрне) җыю, яздыру, тәртипкә салу, туплау, саклау, тәгаенләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, файдалану, тапшыру (тарату, бирү, куллану мөмкинлеге), шәхси үзенчәлекләрен бетерү, чикләп кую, бетерү, юкка чыгару), шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында (http://mtsz.tatar.ru) урнаштыру юлы белән, минем фамилиям, исемем һәм атам исеме (булган очракта) турындагы белешмәләрне затларның чикләнмәгән даирәсенә карый алу мөмкинлеген бирүгә ризалык бирәм.

________________________________________________________________

________________________________________________________________

*(алынган шәхси мәгълүматлар бары тик билгеле бер хезмәткәрләр өчен катгый рәвештә генә мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген бирә торган эчке челтәр буенча яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып тапшырыла ала торган яисә алынган шәхси белешмәләрне тапшырмауны күздә тоткан шартлар күрсәтелә (шәхси белешмәләр субъекты*

*ихтыяры буенча тутырыла)*[1]

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

________________________________________________________________________________

*(алынган шәхси белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыручы оператор тарафыннан шәхси мәгълүматлар бары тик билгеле бер хезмәткәрләр өчен катгый рәвештә генә мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген бирә торган эчке челтәре буенча яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен кулланып тапшырыла ала торган яисә алынган шәхси белешмәләрне тапшырмауны күздә тоткан шартлар күрсәтелә (шәхси белешмәләр субъекты ихтыяры буенча тутырыла)*

Мондый ризалыкны биреп, мәҗбүри рәвештә эш итмәвем, үз ихтыярым белән һәм үз мәнфәгатьләремдә гамәл кылуым турында раслыйм.

Минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә әлеге ризалык конкурс тәмамланганнан соң өч ел үткәнчегә кадәр гамәлдә булачак.

| | | |
|---|---|---|
| ____________________ | ____________________________ | ____________________ ». |
| (дата) | (фамилия, исем, ата исеме) | (имза) |

[1] Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 3 мартындагы 256 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составы бердәм мәгълүмат системасы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмә раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге 890 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләр үтәлергә тиеш.